


# Көллият сулышы

№1 18.10.2022

ДАҺБҮ «Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте»


**Бүген газета санында:**

*Көллият яңалыклары.*

*Беренче адымнар.*

*Ихлас күңелдән.*

*Шигырьләр..*




**Хөрмәтле өлкәннәребез!**

*Алтын көзнең матур бер көнендә дөнья буйлап сезнең бәйрәм билгеләнеп үтелә. Сезнең дә гомер көзегез табигатьтәге гүзәл көзгә тиң булсын иде. Кояшлы, матур көннәр, тәмле җимешләр белән сөендерүче алтын яфраклы агачлар, муллык, куаныч һәм бәхеткә бай мизгелләр сезнең тормышыгызны һәрчак бизәп торсын! Һәммәгезгә дә ныклы сәламәтлек, иминлек, озын гомер, күңел тынычлыгы, якын кешеләрегезнең мәхәббәтен, игътибарын һәм хөрмәтен тоеп, озак яшәвегезне телибез!*

*Сез булганда әле, без – бәхетле.*
*Нур бөркелә сезнең йөзегездән.*
*Бәйрәм сәламе итеп, җылы сүзләр*
*Һәм теләкләр кабул итегез бездән!*




**“Беренче адымнар”**
**1 курс студентларының көллият турындагы беренче фикере, яңа уку йорты аларда нинди тәэсир калдырган икән?**

→ 4 бит



**“Шагыйрә, язучы, педагог Рифә Рахманга – 60 яшь”**

**Үзенчәлекле шәхеснең иҗат җимешләре белән**

→ 6 биттә танышырга мөмкин



**“Шушы түгелмени бәхет?!”**

**Россиянең мәгариф отличнигы, ТАССРның атказанган укытучысы,Арча педагогия көллиятенең легендар директоры Илдус Габдрахман улы Сәгъдиев белән кызыклы әңгәмә**

→ 7 бит

# Көллият яңалыклары



ДАҺБУ "Казан педагогия көллияте" базасында **7-12 нче сентябрь** көннәрендә дистанцион форматта узган **"Яшь профессионаллар"** (WorldSkills Russia)-2022 "Мәктәпкәчә тәрбия" компетенциясе буенча X милли чемпионат финалында 112 нче төркем студенты Жарова Светлана алтын медаль яулады.

*************

**12 нче сентябрьдә «Экстремизмга-юк!»** айлыгы кысаларында Арча стадионында «Иң кәчлеләр уены» командасында экстремаль йөгерү узды. 141 нче төркем студентлары Фәйзуллина Альбина, Сибгатуллин Булат,Хаматова Евгения катнашындагы Арча педагогия көллияте командасы 3 нче призлы урынны яулады

*************



**15 нче сентябрьдә** Лаеш техник-икътисад техникумы (ЛТИТ) нигезендә **"Форпост"** җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр оешмаларының зональ спартакиадасында Арча педагогия көллияте командасы Татарстан Республикасында 2 нче призлы урын алды.

*************

**17 нче сентябрьдә** Арча педагогия көллияте студентлары Арча шәһәре стадионында узган **"Татарстан кроссы-2022"** Республика массакүләм ярышында актив катнашты. Кызлар арасында 1 нче урынны Фәйзуллина Альбина, 2 нче урынны Мөбәракова Алисә (341 гр.). Егетләр арасында 3 нче урынны Низамутдинов Рәхим (241 гр.) алды. Кросста һәр йөгерүдә җиңүчеләр һәм призерлар истәлеккә призлар, грамоталар һәм медальләр белән бүләкләнде.

*************

**21 нче сентябрьдә** безнең көллият студентлары Бәдретдинов И., Гарипов И., Сибгатуллин А. Татарстан Республикасы буенча УГИБДД МВД административ комплексы территориясендә автомобиль йөртүче студентлар арасында үткәрелгән **"Автосессия-2022"** зона конкурсында катнаштылар һәм 3 нче урынны алдылар.

*************

**22 нче сентябрьдә** Арча педагогика көллиятендә һөнәри техник белем көненә 1 км егетләр һәм 500 метр кызлар өчен дистанциядә **кросс буенча ярышлар** узды. Кызлар арасында 1 нче урынны Яруллина Лиана (321 гр.), 2 нче урынны Анисимова Алена (321 гр.), 3 нче урынны Багавиева Гөлшат (131 гр.) алдылар. Егетләр арасында Мәрдәнов Искәндәр җиңү яулады (341 гр.). 2 нче урынга Низаметдинов Рәхим (241 гр.), 3 нче урынга Сәмигуллин Салават (241 гр.) лаек булды.

*************

**23 нче сентябрьдә** көллияттә беренче курс студентлары өчен **"Алга- хыялга таба – 2022"** традицион форумы узды. Әлеге чара төркемнәрне үзара берләштерүгә бер адым булды.

*************

**24 сентябрьдә** көллиятебездә Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, СССРның спорт мастеры **Фәйзрахманов Габделхәй Гыйният улы истәлегенә** волейбол буенча турнирда безнең команда кызлары 1 нче урынны яулады.

*************

**25 нче сентябрьдә** МБУ "Арча спорт мәктәбе" базасында **волейбол буенча** Арча муниципаль районы турнирында Арча педагогия көллиятенең егетләр командасы 2 нче урынны яулады.

# Гөрли студент тормышы..























# Беренче адымнар...



“Миңа Арча педагогия көллиятендә бик тә ошый, чөнки монда мин бик күп дуслар таптым. Баштарак мин уку процессына кереп китәргә авыр булыр дип уйлаган идем, ләкин береаз вакыт үткәннән соң барысына да ияләштем. Көллияттә миңа иң күбе безнең төркем һәм математика дәресләре ошый”.

**Камилә Вәлиева, 112 нче төркем**

“Көллият һәрбер кешенең тормышында бик зур роль уйный. Минем өчен “көллият” сүзе белемне ныгыту белән бәйле буылп тора... Көллиятнең ишеген ачып керүгә үк минем күңелемдә җылы хисләр уяна, чөнки монда сине беркем дә кыерсытмый, киресенчә танышырга, аралашырга телиләр . Көллияттәге тәнәфесләр минем өчен аерым бер могҗиза... Минем кечкенәдән үк укытучы буласым килде, ләкин нәселебездә укытучылар юк. Шулай да, Арча педагогия көллиятен сайларга булым. Җәй буе мин нәтиҗәләрне көттем һәм миңа бәхет елмайды. 15 нче августтан соң укытучы буласымны белгәч, шатлыгымнан елап җибәрдем”.

**Камилә Гарипова, 113 нче төркем**

“Кечкенәдән укытучы булырга хыялландым. Менә хәзер инде хыялымны тормышка ашырам. Көллият төрле юнәлештәге һөнәр ияләре әзерли. Монда уку миңа бик ошый. Укытучылар безгә төпле белем бирәләр. Теләгән кеше төрле түгәрәклргә йөри ала, көллияттә матур чаралар да һәрдаим үткәрелеп тора. World Skills та катнашып, үз көчеңне сынап карарга мөмкин...Көллиятнең бөек шагыйребез Габдулла Тукай исемен йөртүе дә үзе бер горурлык дип саныйм”.

**Розалина Шакирова, 112 нче төркем**

“Көллиятнең гүзәллеге, атмосферасы, бердәм коллективы мине сокландырды... Юкка түгел, педагогия көллияте үз тарихын саклый һәм туган теле, мәдәнияте белән горурлана белүче, дөньяны яхшы якка үзгәртергә теләгән кадрлар әзерли”.

**Камилә Абдуллина, 112 нче төркем**

“Минем кечкенәдән иң зур хыялым – укытучы булу иде. Балаларны укыту, аларга белем бирү – хөрмәткә лаеклы эш. 9 нчы сыйныфы тәмамлагач, хыялымны тормышка ашыру өчен Арча педагогия көллиятен сайладым. Әйе, студент булуы авыр, тик татар халкы “Тырышкан табар, ташка кадак кагар” ди. Әлбәттә, мин бу мәкаль белән килешәм. Теләгеңә ирешү өчен үз өстеңдә эшләргә кирәк. Минем бу эштә иң зур булышчыларым – көллият һәм укытучылар... Мөгаллимнәрнең көләч йөзләре, безгә карата ягымлы карашлары үзе бер маяк, алга таба этәргеч булып тора. Әлбәттә, һәркемгә дә уку, көллият ошап бетмәскә дә мөмкин. Тик, минем уйлавымча, Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятендә белем алу – зур горурлык”.

**Эльвина Иванова, 113 нче төркем**

“Арча педагогия көллияте минем күңелемдә яхшы, матур хисләр уятты. Бу көллияттә минем таныш кешеләрем дә укый. Беренче тапкыр үземнең төркемдәшләремне күргәч тә, алар миңа ачык йөзле, ярдәмчел кешеләр булып тоелдылар... Ни өчен бу көллиятне сайладың дигән сорауга минем болайрак җавап бирәсем килә: әлеге уку йортын бик көчле дип саныйлар һәм монда яхшы, төпле белем бирәләр. Шулай да, беренче көннәрдә уку процессын авыррак кичердем, чөнки яңа кешеләр, дуслар, яңа укытучылар, күңелдә нинди генә хисләр тумый. “Тырышкан малда өмет бар” дигән мәкальне истә тотып, тырышып укырга да, укырга кирәк хәзер!”

**Әлфинә Мөхлисуллина, 113 нче төркем**

# Ихлас күңелдән




**Хөрмәтле Гөлнара Фидаилевна!**

Сезне һөнәри бәйрәмегез – Укытучылар көне белән чын күңелдән котлыйбыз! Сезнең олы хезмәтегез, биргән белемнәрегез кешелек дөньясын алга этәрә, яңа ачышларга илтә.Сез – киләчәк дөньяга, тормышка ишекләрне ача торган ачкычларның хуҗасы! Сез – безнең үрнәк алырлык кешебез. Сез биргән белемнәр, Сезнең үгет-нәсыйхәтегез безгә бүгенге авыр тормышта да дөрес юлдан тайпылмыйча, гел алга барырга ярдәм итә. Атачак таңнарыгыз – аяз, туасы көннәрегез – кояшлы, төннәрегез – тыныч, сәламәтлегегез нык булсын. Безгә, студентларга, белем алыр өчен барлык шартлар тудырганга олы рәхмәтебезне белдерәбез.
Бәйрәм белән Сезне!

**Зур хөрмәтбелән, 412 нче төркем студентлары**

**Кадерле укытучыларыбыз!**

Сезнең турында күпме матур шигырьләр язылган, моңлы җырлар җырланган. Әйтер өчен яңа сүзләр, матур теләкләр инде калмагандыр да сыман, тик гел яңа сәнгать әсәрләре, җылы теләкләр туа тора. Чөнки укытучы һөнәре гади һөнәр генә түгел һәм укытучы – гади кеше генә түгел. Укытучы һәр кешенең тормышында иң мөһим роль уйнаучыларның берсе. Сез һәр кешенең тормышына үз сулышыгызны, үз карашыгызны кертәсез.
Укытучы! Әлеге сүзне ишеткән саен һәр кеше үзенең укытучыларын күз алдына китерә. Укытучыларын истә тотмаган, аларга рәхмәт әйтмәгән бу дөньяда беркем дә юктыр, минемчә.
Хөрмәтле укытучылар! Сезне ихлас күңелебездән бәйрәм белән тәбрик итәбез! Эшегездә, гаиләгездә шатлык-бәхет булуын телибез! Үз эшегезгә, укыткан балаларыгызга, һөнәрегезгә, шул ук вакытта туган телебезгә тугры булып калыгыз. Саулык-сәламәтлек, иҗади уңышлар телибез Сезгә!

**Богаутдинова Диләрә, 311 нче төркем**




**Хөрмәтле Алия Фанавилевна!**

Сезне ихлас күңелемнән Укытучылар көне белән тәбрик итәм. Шушы 6 ел уку дәвамында, сез минем өчен үз һөнәрегезнең остасы гына түгел, ә чын якын кешем, үрнәк, икенче әнием булдыгыз. Сезнең хезмәтегез бәяләп бетергесез, берни белән дә чагыштырып булмый. Сез мине барлык осталыкка да өйрәттегез, төрле конкурсларда катнашып, сәләтемне югалтмаска өйрәттегез. Бик зур рәхмәт сезгә! Алдагы эшегездә зур уңышлар, иминлек телим. Шундый ук үрнәк, үз эшен ахырына хәтле җиткереп бетерүче педагог булып калыгыз. Сезгә бик тәртипле, сәләтле студентлар телим. Бәхетле булыгыз!

**Газизова Ләйсән, 431 нче төркем**

**Хөрмәтле Жанна Вениаминовна!**

Сезне чынкүңелдән һөнәри бәйрәмегез – Укытучылар көне белән котлыйбыз. Бу көндә матур теләкләр бик күп булыр, шуңа да без сезнең белән булган күңелле вакытларны искә төшерергә уйладык. 1 нче курстан бирле сезнең ярдәмегез белән без зур уңышларга ирештек: физик, практик һәм теоретик аң-белемнәребезне баеттык. Ә сез хәтерлисезме безнең белән беренче физкультура дәре сен?32 без 32 төрле формадан сезнең каршыгызга кереп бастык. Ииии, әрләдегез безне...
Шул көннән бирлебашка формасыз сезнең дәрескә кергән булмады. Сезнең белән булган дәресләр, безнең күңелләрдә якты хатирә булып истә калыр. Мәсәлән, карлар эреп күлләвекләр җыелганда, кеше чаңгыдан кереп спортзалга күчкән чакта, без кулга чаңгылар тотып, чаңгы трассасы буйлап дәресләр үткәрдек.Ә сез белсәгез иде, ничек без төннәр буе практикумнан считалка, физкультминутка, уеннар ятладык. Сезнең дәрескә соңа калу, безгә зур гөнаһ иде, ә инде соңа калсан синең фоткаң белән исем фамилияң әти-әниләргруппасында булу гарантировано иде.
Шулай да безнең белән үткәрелгән һәр минутны сагынып искә алабыз.
Коридорда сзне күрү дә безнең өчен зур бәхет. Алдагы эшегездә дә сезгә зур уңышлар телисебез килә. Безнең кебек акыллы студентларыгыз күбрәк булса иде дигән теләктә калабыз.

**Зур хөрмәт белән, 431 нче төркем студентлары**

**Хөрмәтле укытучыларыбыз!**

Сезне һөнәри бәйрәмегез – Укытучылар көне белән чынкүңелдән котлыйбыз!
Үз һөнәрегезгә бирелгәнлек, зирәклегегез һәм күңел байлыгыгыз өчен рәхмәтебезне белдерәсебез килә. Сез безне яхшыны яманнан аерырга өйрәткән кадерле остазларыбыз.
Сез – түзем дә, сабыр да, югары культуралы һәм гаять зур белем байлыгы булган шәхес тә.
Без Сезне ихтирам итәбез. Сезгә эшегездә зур уңышлар, иминлек һәм безнең шикелле яхшы студентлар телибез.

**Ихсанов Ильмир, 412 нче төркем**

## Шагыйрә, язучы, педагог Рифә Рахманга – 60 яшь...



***Рифә РАХМАН*** – шагыйрә, прозаик, галимә. ТАССРның Кукмара районы Мәмәшир авылында туа. Арча педагогия училищесын, Казан дәүләт университетының филология факультетын тәмамлый. 1996 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.«Онытырмын димә», «Йолдызлар төстән язганда», «Таулар һаман ерак» һ. б. исемдәге күпсанлы китаплар авторы. Ф.Хөсни, Г.Исхакый исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Рифә Рахман 18 сентябрьдә үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Шул уңайдан, Арча педагогия көллияте коллективы исеменнән аны гомер бәйрәме белән ихлас күңелдән тәбрик итәбез. Хөрмәтле Рифә ханым, Сез үзегезнең иҗат җимешләре нигезендә кешеләргә матурлык, яктылык, чисталык таратасыз. Алдагы көннәрдә дә иҗат чишмәләрегез саекмасын, ә бәхет ишекләре сезнең алдыгызда һәрвакыт ачылып торсыннар. Сөеп-сөелеп, кадер-хөрмәткә төренеп яшәргә насыйп булсын!

### Яфрак-яфрак.

**Кар коела яфрак-яфрак булып:
Шул хәл кышны көзгә якынайта.
Көзнең агы булмас димә икән!
Сукмакларда кар-кар яфрак ята.**

**Куркытсаң да, миңа өмет бирми,
Рәхәт тә соң: барам янәшәңдә.
Кар-кар яфрак. Яфрак-яфрак сукмак...
Их, яшәргә иде, их яшәргә!**

**Ак яфраклы йөз-мең сукмакларны
Их, үтәргә иде иренмичә.
Их, сөяргә иде сибелмичә,
Кеше көнләвенә бирелмичә.**

**Көзнең агы булмас димә икән:
Гомер көзем минем нинди якты.
Көзне ап-ак иткән сукмакларга
Төшкән кары учтай яфрак чаклы.**

**Синең кулга әллә тотынганга,
Рәхәт тә соң: барам ипле генә.
Эзне эзгә әле кушмый гына,
Синең яннан ерак китми генә.**

### Минем туу

**Йолдызларның аңы киткән чакта,
Йолдызларның төсе уңганда –
Туганмын мин –
Инеш, елга суы
Ярларына тәмам тулганда.
Күзләреңнән йолдыз тама, дисез,
Яшьне нәни йолдыз күрәсез –
Исәр йолдыз кебек яшисең, дип,
Нигә мине һаман сүгәсез?
Гаҗәпмени йолдыз нурларына
Минем шулай ия булуым?
Моңа сәбәп
Яңа йолдыз белән
Бер вакытта минем тууым.
Бик газаплы, дилэр, йолдызларның
Яралуы галәм эчендә.
Мин дә йолдыз кебек җан алганмын…
Шуңадыр да йолдыз төсендә.
Йолдызларның һушы киткән чакта
Җиңелмени исән калуы?!
Шундый еллар бит бу,
Шундый еллар!!!
Сүнәм,
Кабат китәм кабынып.
Күкнең һичбер буп-буш торганы юк.
Сүнсәк,
Башка йолдыз табылыр.
Ул без булмас,
Син дә, мин дә түгел –
Килер буыннарның һичкеме.
Тик алар да йолдызларга карар,
Шуннан очып килгән шикелле.**

# Илдус Габдрахман улы Сәгъдиев:

# Шушы түгелмени бәхет?!



**1. Арча педагогия училищесына килгән беренче көнегезне хәтерлисезме? Ничегрәк булды ул?**

- Арча педагогия училищесына без беренче тапкыр Флера апаң белән бергә җитәкләшеп 1963 нче елда килдек. Безне Бөек ватан сугышында катнашкан, орден-медальләр белән бүләкләнгән, заманында райком секретаре булган, искиткеч кешелекле, дәрәҗәле шәхес директор Мөнәвир Гәрәй улы Ибраһимов эшкә алды. Ул вакытта педагогия училищесында "Әлифба" авторлары Сәләй Гата улы Вәгыйзов белән Рәмзия Гыйләҗ кызы Вәлитова кебек олы шәхесләр дә эшли иде. Аларны оныту мөмкин түгел. Шул укытучыларга охшарга тырышып эшне башлаган кешеләр без.

**2. Җитәкчегә зур коллективны тәртиптә тоту өчен нишләргә кирәк? Ул нинди булырга тиеш?**

- Башта укытучы булып, аннан соң 7-8 ел завуч булып эшләдем. 1981 нче елдан башлап 2002 нче елны кертеп директор итеп куйдылар. Арча педагогия училищесында һәрвакыт көчле, бердәм, бер-берсенә ярдәм кулы сузарга әзер булган укытучылар эшләде һәм эшли. Җитәкче кеше нинди булырга тиеш дигәндә, мин болай җавап бирер идем: беренче чиратта, ул коллективтагы һәрбер кешенең хезмәтен күрә белергә, аңа дөрес итеп бәя бирергә, кирәк вакытта ярдәм кулы сузарга да әзер булырга тиеш.

**3. Училищеда эшләү дәверендә булган иң кызыклы вакыйга?**

- Училищеның тормышы элек-электән кызыклы вакыйгаларга бик бай булды. Иң күңелгә кереп калганы көллиятебезгә атарстанның күренекле язучылары килү һәм алар белән күзгә-күз очрашып сөйләшү иде. 15-20 шәр язучы җыелып килгән вакытлар истәлек булып хәтергә кереп калган. Ул вакытта әле студентлар әдәбият белән күбрәк кызыксыналар иде: язучыларга сораулар биреп, алардан автогрофлар алган мизгелләре дә исемдә .

**4. Сезнеңчә бүгенге заман укытучысы нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?**

- Бүгенге заман укытучысының төп максаты – үзе укыта торган фәненең методикасын югары дәрәҗәдә белү, укучыларны ярату һәм аларны якын итү. Студентларның киләчәге турында уйлап, аларга үз юлларын табарга ярдәм итә алу – укытучының зур бурычы. Һәр укучыңның уңышына сөенү, кайбер җитешсез якларын төзәтә белү дә мөһим. Андый укытучыга укучылары да гомер буена рәхмәтле була. Хәтта 30, 40, 50 шәр ел үтсә дә, яраткан мөгаллимең онытылмый ул. Укытучының бәхете дә шуннан тора

**5. Сез үзегезне ничә яшьтә итеп хис итәсез? Үзегезне өлкәннәр рәтенә кертәсезме?**

- Кайчандыр яшь вакытларда 50 яшькә җиткән кешеләрне күргәч, ничек шул яшькә җитеп була икән ул дип бик аптырый идем. Менә бит Аллага шөкер 50се дә булды, 60, 70, 80, 85ше дә узып китте.
Ә яшисе килә! Кайбер вакытта үзеңнең олы яшьтә икәнлегеңне онытып та җибәрәсең. Яңалыкларны да белеп торасы килә. Аннан соң мин бик бәхетле дип саныйм үземне. Янәшәмдә Флера апаң, балаларыбыз, оныкларыбыз, онықчыкларыбыз. Алар мине бәхетле итә. Каршымда гомер буе эшләгән педучилищам ялт итеп тора, матур итеп эшли. Хәзерге вакытта да ул Татарстанда гына түгел Россия күләмендәге иң алдынгы уку йортларының берсе булып санала. Бәхет түгел мени бу? Шуңа күрә дә бит яшисе килә...

**РЕДКОЛЛЕГИЯ:**

***Рузилә Каюмова***

***Гөлия Шиһабеддинова***

***Виктория Анохина***